**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "САВРУШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ"**

**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

№ 3 11 ноябрь 2025 ел

**«Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Савруш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 матрындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Уставы 24 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы "Савруш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРы:

1. 2025 елның 21 ноябрендә Түбән Савруш мәдәният йорты бинасында 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1.Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- Савруш авыл җирлегенең Савруш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау. (Вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау һәм ташу, вак ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, юлларны кыш көне карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр һәм җайланмалар сатып алу; шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

**2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Савруш авылы өчен янгын сүндерү өчен савытлар һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу).

**3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм**

**транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Савруш торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (светодиодлы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру; үсентеләрне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу )).
- Савруш торак пункты чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Савруш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге башлыгы: И.М.Сафин